**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 25 март

№ 171

г. Казань

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү үткәрү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 4 пунктның 3 пунктчасы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясындагы 4 пунктның 3 пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Теркәлгән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү үткәрү тәртибен расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\171.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 25 март, 171 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү үткәрү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 4 пунктның 3 пунктчасын, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясындагы 4 пунктның 3 пунктчасын тормышка ашыру максатларында җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү тәртибе Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының (алга таба – Министрлык) җирле бюджетлар үтәлеше турында еллык хисапларны тикшерүләр үткәрү буенча (алга таба – тикшерү, еллык хисап) эшчәнлеген регламентлаштыра.

1.2. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 4 пункт, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясындагы 4 пункт нигезендә билгеләнә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары үтәлеше турында еллык хисаплар тикшерелергә тиеш.

1.3. Тикшерүнең максатлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә (алга таба – муниципаль берәмлек) җирле бюджет үтәлешен оештыруның Россия Федерациясенең бюджет законнарына, Татарстан Республикасы законнарына һәм бюджеттагы хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган бүтән норматив хокукый актлар таләпләренә туры килүен билгеләү;

хисап финанс елы өчен җирле бюджет акчасын баш бүлүчеләрнең (бүлүчеләрнең), җирле бюджет акчасын алучыларның, җирле бюджет керемнәре баш администраторларының (администраторларының), җирле бюджет дефицитын финанслау чыганаклары баш администраторларының (администраторларының) бюджет хисаплылыгына туры килү өлешендә еллык хисап күрсәткечләренең тулылыгын һәм дөреслеген билгеләү;

бюджет акчасыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм җирле бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәрен арттыру буенча чараларның фактта гамәлгә ашырылуы муниципаль берәмлекнең бюджет акчасыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм җирле бюджетның салым һәм салым булмаган керемнәрен арттыру буенча чаралар турында Министрлык белән килешү (алга таба – Килешү) нигезләмәләренә туры килүен билгеләү.

1.4. Тикшерү объектлары түбәндәгеләр:

муниципаль берәмлекнең финанс органы (алга таба – финанс органы);

җирле бюджет акчасын баш бүлүчеләр, җирле бюджет керемнәре баш администраторлары, җирле бюджет дефицитын финанслау чыганаклары баш

администраторлары (алга таба – җирле бюджет акчасының баш администраторлары).

1.5. Тикшерүне Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары үткәрә.

1.6. Еллык хисапларны тикшерүләр үткәрү законлылык, объективлык, нәтиҗәлелек, бәйсезлек, һөнәри компетенция, нәтиҗәләрнең дөреслеге һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнә.

1.7. Министрлыкның вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы:

а) язма формадагы дәлилле сорату нигезендә тикшерүләр үткәрү өчен кирәкле мәгълүматны, документлар һәм материалларны, язмача һәм телдән аңлатмаларны соратырга һәм алырга;

б) тикшерүләрне гамәлгә ашырганда хезмәт таныклыкларын һәм Министрлыкның тикшерү үткәрү турында боерыгы күчермәсен күрсәтеп, тикшерү объектлары торган биналарга һәм территорияләргә керергә;

в) тикшерү үткәргәндә кирәкле экспертизалар үткәрергә һәм (яки) мондый экспертизалар үткәрү өчен бәйсез экспертларны җәлеп итәргә.

1.8. Министрлыкның вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә бурычлы:

а) билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендәге норматив хокукый актлар таләпләрен сакларга;

б) тикшерү объекты җитәкчесен яки тикшерү объектының вәкаләтле вазыйфаи затын Министрлыкның тикшерү үткәрү турында боерыгы, тикшерү үткәрүне туктатып тору, торгызу һәм үткәрү вакытын озайту хакында, тикшерү төркеме составы үзгәрү турында боерыгы, шулай ук тикшерү үткәрү нәтиҗәләре күчермәләре белән таныштыра;

в) җинаять составы билгеләре булган гамәлләр кылу (гамәлләр кылмау) факты ачыкланганда, мондый факт турында мәгълүматны һәм (яки) мондый фактны раслый торган документларны һәм бүтән материалларны хокук саклау органнарына юллый.

## 2. Тикшерүләрне планлаштыру

2.1. Тикшерү Министрлык тарафыннан тиешле елга тикшерүләр үткәрү планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр үткәрү планы, Татарстан Республикасы Хисап палатасы үткәрә торган еллык хисапларны тикшерү турында мәгълүматларны исәпкә алып, Министрлык тарафыннан төзелә.

Тикшерүләр үткәрү планы тиешле елда тикшерүләр үткәрү планлаштырылган муниципаль берәмлекләр исемен, тикшерүләр үткәрү срокларын үз эченә ала.

Тиешле елда тикшерүләр үткәрү планы планлаштырылган ел алдындагы елның 25 декабреннән соңга калмый Министрлык боерыгы белән раслана.

2.2. Тикшерү үткәрү өчен нигез булып Министрлык боерыгы тора.

Тикшерү үткәрү турында боерыкта түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) тикшерү исеме;

б) тикшерү объектлары исеме;

в) тикшерү төркеме җитәкчесе исемен күрсәтеп, тикшерү төркеме составы;

г) тикшерү башлану датасы һәм аны үткәрү вакыты.

## 3. Тикшерү үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

3.1. Тикшерү максатларына ирешү кысаларында түбәндәгеләргә мөнәсәбәттә тикшерү объектлары эшчәнлеген документаль өйрәнү буенча тикшерү гамәлләре башкарыла:

а) җирле бюджетны планлаштыру;

б) җирле бюджетны карап тикшерү һәм раслау;

в) җирле бюджетка үзгәрешләр кертү;

г) Россия Федерациясе бюджет законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм Килешү нигезендә җирле бюджетны үтәү;

д) Килешүдә күрсәтелгән чараларны башкару турында хисап;

е) әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән документларны формалаштыру.

3.2. Тикшерү үткәрү барышында тикшерү предметы турында белешмәләр һәм мәгълүматларны үз эченә алган документларны өйрәнү гамәлгә ашырыла, шул исәптән:

а) җирле бюджетны үтәү процессын регламентлаштыручы муниципаль хокукый актларны;

б) җыелма бюджет язуын;

в) муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләре реестрын;

г) җирле бюджетка табыш керү фаразын;

д) җирле бюджет керемнәрен, чыгымнарын һәм дефицитын финанслау чыганакларын исәпләү буенча счетлардагы операцияләрне раслый торган беренче документларны, бюджет исәбе регистрларын, муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен исәпкә кую (исәптән төшерү) өчен нигез булган документларны, җирле бюджет акчасы белән операцияләр кылуны раслый торган финанс хисаплылыгын;

е) җирле бюджет акчаларының баш администраторларының еллык бюджет хисаплылыгын;

ж) Россия Федерациясе бюджет законнары һәм бюджеттагы хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган бүтән норматив хокукый актлар белән каралган хисаплылыкны.

3.3. Тикшерүнең дәвамлылыгы 30 эш көненнән артмый.

Соратылган документлар бирелгән һәм (яки) каршы тикшерүләр үткәрелгән вакыт аралыгы тикшерү үткәрү вакытына кертеп исәпләнелми.

Түбәндәге очракларда тикшерү үткәрү вакыты тикшерү төркеме җитәкчесенең дәлилле мөрәҗәгате нигезендә Министрлык боерыгы белән иң күбе 15 эш көненә озайтылырга мөмкин:

а) тикшерү объектлары саны артканда (финанс органыннан тыш);

б) тикшерү барышында өстәмә тикшерү таләп ителгән мәгълүмат алынганда.

3.4. Тикшерү нәтиҗәләре тикшерү акты белән рәсмиләштерелә, ул ике нөсхәдә төзелә һәм тикшерү тәмамланган көннән соң өч эш көне эчендә Министрлыкның тикшерү төркеме җитәкчесе һәм финанс орган җитәкчесе тарафыннан имзалана.

тикшерү төркеме җитәкчесе тикшерү актының бер нөсхәсен аңарга имза куелган көннән соң өч эш көне эчендә финанс органына тапшыра (җибәрә). Актның икенче нөсхәсе Министрлыкта кала.

3.5. Тикшерү нәтиҗәләре:

а) хисап финанс елына җирле бюджет үтәлеше турында хисапның дөреслеге хакында нәтиҗәләрне үз эченә алырга тиеш;

б) муниципаль берәмлектә бюджет процессларын оештыру мәсьәләләрен җайга салучы муниципаль хокукый актларның Россия Федерациясе бюджет законнары һәм бюджеттагы хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган бүтән норматив хокукый актлар таләпләренә туры килүен (туры килмәвен) чагылдырырга тиеш;

в) Килешүне түбәндәге өлешләрдә үтәүне (үтәмәүне) чагылдырырга:

җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә караган мәсьәләләрне хәл итү белән бәйле булмаган чыгым йөкләмәләрен билгеләмәү һәм үтәмәү;

муниципаль хезмәткәрләр хезмәте өчен түләүгә һәм (яки) муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарын карап тотуга чыгымнарны формалаштыру нормативларын арттырмау;

хисап елының һәр аеның беренче көне торышына җирле бюджетның вакыты чыккан кредит бурычлары булмау;

бюджет акчасын файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән бүтән шартлар;

г) җирле бюджет акчалары баш администраторларының бюджет хисаплылыгы күрсәткечләренең хисап финанс елына җирле бюджет үтәлеше турында хисап күрсәткечләренә туры килүен чагылдыру.

3.6. Финанс органы тикшерү актына язмача кире кагуны аны алган көннән соң биш эш көне эчендә бирергә хокуклы. Күрсәтелгән кире кагулар тикшерү материалларына теркәлә.

---